# МӘГАРИФ

АЙЛЫК ИҖТИМАГЫЙ-ПЕДАГОГИК ҺӘМ ФӘННИ-ӘДӘБИ ЖУРНАЛ

ОЕШТЫРУЧЫЛАР ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХӨКҮМӘТЕ, МӘГАРИФ МИНИСТРЛЫГЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

**№ 9 (703) СЕНТЯБРЬ** 1918 елның ноябреннән чыга Татар телендә



Баш мөхәррир
**Фәрит ШӘРИФУЛЛИН**


Редколлегия

**Румин АКБАШЕВ,**
**Мәҗит ВӘЛИУЛЛИН**
(баш мөхәррир урынбасары)
**Тихния ГАЙФУЛЛИНА,**
**Миркасыйм ГОСМАНОВ,**
**Рәшит ИСЛАМШИН,**
**Зәфәр МИФТАХОВ,**
**Гайнан МӨХӘММӘТҖАН**
(җаваплы сәркатип)
**Айдар САФИН,**
**Роза СЫРОМОЛОТОВА,**
**Фарис ХАРИСОВ,**
**Рамил ХӘЛИУЛЛИН,**
**Кәмәрия ХӘМИДУЛЛИНА,**
**Рүзәл ЮСУПОВ,**
**Фәүзия ЮСУПОВА,**
**Фәрит ЮСУПОВ,**
**Миңнехан ӘХМӘТҖАНОВ.**

Бүлек мөхәррирләре
**Ә. М. ЛАТЫЙПОВ** (туган тел һәм әдәбият төрле фәннәр)
**Г. М. ШӘФИГУЛЛИНА** (рус теле һәм әдәбияты, мәктәпкәчә тәрбия)
**Э. М. ШӘРИФУЛЛИНА** (физика, математика, башлангыч мәктәп)
**М. Х. ВӘЛИЕВ** (педагогика-методика, мәктәп һәм гаилә)
Җаваплы сәркатип урынбасары
**Р. Г. САБИРОВА.**
Баш бухгалтер
**С. З. САБИРҖАНОВА** 49-36-78



| Телефоннар | |
|---|---|
| Баш мөхәррир | 53-57 35 |
| Баш мөхәррир урынбасары | 53-39-15 |
| Җаваплы сәркатип | 49-36-82 |
| Бүлек мөхәррирләре | 49-36-80 |
| | 49-36-78 |


**Хатлар өчен адрес**
420066 Казань
ул. Декабристов 2
Редакция журнала
«Мәгариф» а/я 47



© «Мәгариф» 1994 ел


# БУ САНДА


**АҢ-БЕЛЕМ ВӘ ЭШ-ГАМӘЛ**

**Мөхәммәтҗанова Г.**— Мәгариф адымнары 2
Бу уку елында 4

**БАШЛАНГЫЧ КЛАСС**

**Саттарова Н.**— II класста фонетик анализ 6
**Николаева И.**— Әлифба дәресе 8
Тормыш иминлеге нигезләре 9

**РУС БАЛАЛАРЫНА — ТАТАР ТЕЛЕ**

**Юсупов Ф., Гарифуллин В., Гарифуллина М.**— IV класс (Дәвамы) 11
Татарча сөйләшергә өйрәтүнең башлангыч чоры өчен программа 14

**ТУГАН ТЕЛ ҺӘМ ӘДӘБИЯТ**

**Галиуллин Т.**— Заман таләбе 19
**Тумашева Д.**— Программа һәм дәреслек (Дәреслекләрне тикшерү йомгаклары) 21
**Харисова Ч., Харисов Ф.**— Ышанычлы юлдаш булсын 24
**Исламов Ф., Закирҗанов Ә.**— Яңа дәреслек 26

**РУССКОЕ СЛОВО**

**Карпеева Т.**— Прочитаем «забытый» роман (Изучение романа И А Гончарова «Обломов») 27
**Ахбарова Г., Скиргайло Т.**— Новое в работе методических объединений 30
**Саттарова Н., Феоктистова Л.**— На уроках — дидактические игры 31
**Умарова Л., Фаттахова Н.**— Новый учебник для VIII класса 33

**КУЛЬТУРА И ИСТОРИЯ ТАТАРСТАНА**

**Гафаров И.**— О чем молчат учебники истории? (Продолжение) 35

**ГЫЙЛЕМ ДӨНЬЯСЫНДА**

**Исмәгыйлева Ф.**— Ай булмаса, йолдыз бар 39
Халык тәрбиясе (Татар халык педагогикасы программасы) 42
Базар икътисадына кереш 45
«XVIII гасырларда гарәпләр» темасына биремнәрнең җаваплары 47
Бәйгедә — яшь химиклар 49
Тормыш иминлеге нигезләре (V—XI класслар өчен яңа программа) 51

**КЛАССТАН ТЫШ ЭШЛӘР**

**Новиков А.**— Яшь туристлар түгәрәге 53

**МӘКТӘПКӘЧӘ ТӘРБИЯ**

**Гарифҗанова Р.**— Икмәк өстәлгә ничек килә? 55

**СЕЗГӘ, ӘТИ-ӘНИЛӘР, МӨГАЛЛИМНӘР**

**Вяселева А.**— Әдәп төбе — күркәм гадәт 56
**Вәлиева А., Хәйруллина Ф.**— Яшь баланы ашату 57
Ата-аналарга педагогик-психологик белем бирү концепциясеннән (Ахыры) 59
Сез сораган идегез 61
**Закирова Э.**— **Яшь талантлар.** Кушылып җырлыйсы килә 62

*Гыйлем дөньясында*

# Ай булмаса, йолдыз бар...

Фәйрүзә ИСМӘГЫЙЛЕВА, АДПИ доценты

Мәктәпләрдә укыту-тәрбия эшен милли кануннарыбызга нигезләү; халкыбызның рухи хәзинәләренә, тарихына, тәгълим-тәрбия тәҗрибәсенә мәхәббәт, кызыксыну, хөрмәт хисләре тәрбияләү чараларыннан һәм ысулларыннан файдалану гадәти күренеш булып китте. Шунысы куанычлы: бу мөһим эшкә барлык мөгаллимнәр дә катнаша башлады. Мәсәлән, астрономия фәне дә үзенең беренче яралгыларын күк йөзен, кояш, ай, йолдызларны өйрәнү, күзәтү нәтиҗәсендә туган тәҗрибәсеннән ала. Тупланган тәҗрибә сынамыш, мәкаль, әйтем, табышмак, әкият, риваять, җырлар булып, халык күңелендә уела килгән. Астрономия дәресләрендә балаларны алар белән таныштыру — тормыш, заман таләбе. Буыннар чылбырының бу юнәлештә дә өзелмәве бик мөһим.

Вакыты-вакыты белән күңелгә: «Халкыбыз әллә күк җисемнәренә генә карап яшәгән, иҗат иткән инде?» — дигән фикер килә. Чынлап та, ай-йолдызлар, җил-яңгырлар аның рухына — егәр, күңеленә — моң, зиһененә — илһам, күзләренә үткенлек биргән шул.

Безнең төрки бабаларыбыз гомер-гомергә талантлы сәүдәгәр булган. Илләр гизәргә, дөнья күрергә яраткан. «Йөргән таш шомара, яткан таш мүкләнә» кагыйдәсеннән чыгып, үзе өчен кирәкле ачышлар ясаган. Компассыз, карталарсыз да, ай-йолдызларга, кояш йөрешенә карап, чүлләр, далалар аша юлын салган. Күргән-белгән, тапкан-өйрәнгән, сизелгән һәм тоелганнардан чыгып, матур яңгырашлы, тирән мәгънәле, үткен сүзле мәкаль һәм әйтемнәр, табышмаклар, риваятьләр, мәзәкләр, җырлар уйлап чыгарган.

Хәзер шуларның кайберләрен искә төшерик:

— Табак тулы җиз төймә, кулым сузып алалмыйм. (Күк, йолдызлар.)

— Вак кынадыр үзләре, ялтырыйдыр күзләре. (Йолдызлар.)

— Бер көтүче мең сарык көтә. (Ай һәм йолдызлар.)

— Төнлә баксам — күк тулган.
Иртән баксам — юк булган. (Ай-йолдызлы күк йөзе.)

Яки:

— Ай белән кояш берәр генә була.

— Кояш бик зур, әмма аны капларга бик кечкенә болыт та җитә

— Җидегән йолдызның койрыгы таңга сузылыр.

Алга таба ай-йолдызларга бәйле сынамышларга күчәбез:

— Йолдыз атылса, җил булыр.

— Йолдыз тирәсендә кара алка булса, яңгыр булыр.

— Йолдыз куе күренсә, аяз булыр.

Дәрес ахырында кояш, ай-йолдызлар образ итеп алынган җырлар җырларга мөмкин:

Һаваларда йолдыз иләк-иләк,
Җидегән йолдыз бик сирәк;
Ачы ла дөньяны көтәр өчен
Арысландай батыр ир кирәк.

Ай белән кояш бер генә,
Йолдыз сиксән мең генә;
Кавышырбыз дигән идек,
Кавышып булмый тиз генә.

Җырларның төзелешенә генә карагыз. Аның беренче өлешендә табигать, ай-йолдызлар, кояш сурәтләнә. Икенче өлешендә — хис-кичерешләр. «Табигать һәм кеше» — бергә гомергә. Кеше — табигать дөньясының аерылмас бер әгъзасы.

Кереш буенча «Астрономик күзәтүләр һәм телескоп» дигән темага икенче дәрестә, билгеле булганча, укучылар астрономиянең фәнни тикшерену методлары белән танышалар, телескопның төзелешен тикшерәләр. Гыйльми һәм гамәли астрономик күзәтүләрнең үзенчәлекләрен билгеләгәндә, укучыларга берничә фольклор үрнәкләре тәкъдим итела һәм, шулардан чыгып, нәтиҗәләр ясала.

«Астрономиянең гамәли нигезләре» бүлеген өйрәнү өчен программада 5 дәрес каралган. Аның аерым темаларына багышланган дәресләргә кирәкле фольклор үрнәкләрен түбәндәгечә билгеләп куярга мөмкин булыр иде.

**Беренче дәрес. «Йолдызлыклар. Йолдызлар картасы. Күк координатлары» темасы.**

Йолдызларны төркемнәргә бүлү — халыкка хас күренеш. Җидегән, Чүмеч, Бизмән, Көянтә йолдызлар — татарларда бик борынгыдан билгеле йолдызлыклар. Шуның өчен дә аларның халык авыз иҗатында чагылыш табуы — табигый хәл.

1. Җидегән йолдыз җиде әйләнә
Җиде төн уртасында
Җидегән йолдыз нурлары бар
Ике бит уртасында.

2. Алты кыз һәр төн саен
Көянтәләп су китерә.
Унбер егет бергә җыелып,
Читтән күзләп, төн кичерә.
(Өлкәр һәм Көянтә йолдызлар )

3. Казыкка бәйләнгән ике атым дулый,
Дуласа да бер тирәдән китә алмый.
(Тимерказык, Акбүзат, Күкбүзат йолдызлары.)

4. Берсе ак, икенчесе күк ике атны тимер казыкка бәйләп куйганнар, имеш. Шул казык тирәсеннән китә алмыйча утлап йөргәндә аларны җиде карак (Җидегән йолдыз) урлап китәргә ниятләгән. Караклар Акбүзат һәм Күкбүзат артыннан әй чабалар, әй чабалар икән... Әле хәзер дә куып җитә алганнары юк, ди. Җирдә калганнары шул чабышны, тын да алмыйча, кымшанмыйча, һаман күзәтә икән...

Тимерказык, ягъни Котып йолдызы хәрәкәт итми һәм һәрвакыт Төньяк Котып ягын күрсәтә. Шуңа күрә дә ул бик борынгы заманнардан бирле юл-сәфәр йөрүчеләр өчен ышанычлы табигый ориентир булып хезмәт иткән.

Акбүзат һәм Күкбүзат — Тимерказык (Котып) йолдызы тирәли әйләнүче йолдызлардан. *Аларның исемнәре дә җисемнәренә* туры килеп тора. Беренчесе шактый якты булып яна, ә икенчесе, аның белән чагыштырганда, тоныграк булып күренә.

**Икенче дәрес. «Эклиптика. Кояш һәм Айның күренүле хәрәкәте».**

Укытучы бер әкият сөйли.

**Ай белән Кояш.**

Борын-борын заманда Кояш белән Ай Җир йөзен бер урында гына торып яктыртырга карар кылганнар. Барча кош-корт, җәнлекләр моңа риза булган. Әмма Ярканат каршы төшкән.

— Кояш белән Ай бер генә җирдә торсалар,— дигән ул,— җил дә бер генә яктан исәр, агачлар кәкре булып үсәр, игеннәр дә кояш төшкән җирдә генә өлгерер.

Бу фикергә барысы да кушылган. Ай белән Кояшка бер генә җирдә тормаска, әйләнеп йөрергә кушканнар.

Кеше тормышында зур роль уйнаганга, халык Кояш барлыгын хәтта шаян сөйләмнәрендә — мәзәкләрдә дә онытмый.

Әүвәл заманда бер малай ураза тоткан. Кояш баеганын түземсезлек белән көтә икән бу. Менә бервакыт, кояш офыкка авышкач, өйгә йөгереп кергән дә:

— Әни, авызны ачыйк инде! — дигән.

— Кояш баемаган әле, улым,— дигән әнисе.

— Нигә баемасын? Безнең кояш әллә кайчан урман артына төшеп китте инде. Баемаган кояш безнеке түгел, башка кешеләрнеке ул, ашарга бир миңа! — дигән.

«Ерактагы кояш җылы була, якын килсәң, пешерә», дигән гыйбарә бар. Үзара татулыклары чамалы булган туган-тумачаның бер-берсеннән ераграк яшәве хәерле. Шул чагында алар арасындагы мөнәсәбәтләр җылырак, якынрак була... Шул турыда беркадәр ирония катыш әйтелә торган бу гыйбарә үзенең туры мәгънәсендә — таб гать күзәтүе буларак та игътибарга лае Фәнни исәпләүләр күрсәткәнчә, безнең ки лекләрдә Җир 22 июнь көнне Кояштан җ лылыкны һәм яктылыкны 22 декабрьдәге караганда 600 мәртәбә күбрәк ала ике Ә бит 22 июнь — ул җәйге кояш торгы лыгы көне, кояшның күк гөмбәзендә югарыга күтәрелә торган вакыты. Шул булгач, чыннан да «ерактагы кояш җыл якты», дип әйтергә нигез бар.

**Өченче дәрес. «Ай хәрәкәте. Кояш һ Ай тотылу».**

Укытучы дәресне мәкаләләр һәм җ әйтеп башлый.

Ай тулса, йолдызлар сыегая. Ай тулг кителә. Ай якты, әмма җылытмый. I күктә ике ай булмас.

| | |
|---|---|
| Ай тулганда бөтен була, | Икебез ике илләр, |
| Кимегәндә кителә. | Аерым гомер ите |

Күргәнебезчә, кешеләр элек-электән җисемнәре, алардагы үзгәрешләр, яңа тулу, кояш һәм ай тотылу белән кызыкс ганнар. Моннан үзләренә отыш та ал нар. Ай тууның үзенчәлегенә карап, кı чәк көннәргә, ай буена һава хәлен дә б гели алганнар.

Яңа ай белән җил булса, бөтен ай буена булыр.

Яңа айның очлары нәзек күренсә, салкы лыр

Яңа айның югары башы җәелебрәк; т башы урак кебек бөгелебрәк торса, кыш айның унбишенә кадәр салкын булыр. Әгәр ры башы бөгелеп, түбән башы җәелеп т унбишенә чаклы салкын һәм җил булыр, ү шеннән соң юеш, былчырак булыр.

Әгәр яңа ай бик ачык ялтырап күренсә, кын булыр.

Әгәр яңа ай нечкә күренсә, ай буена ачык булыр.

Әгәр яңа ай саргылт булып, калын күр ай буе юеш булыр.

Ай караңгы булып торса, һава юеш, кє җепшек булыр.

Әгәр ай ачык булып, ялтырап торса, булыр.

Ай тирәсендә кызыллык алка кебек б тиз бетеп китсә, аяз булыр.

Ай тулы вакытта саф һәм якты булы тырап торса, һава яхшы булыр

**Дүртенче дәрес. «Вакыт һәм календ**

Халык астрономиясендә бик тә гад кыт үлчәмнәрен очратырга мөмкин: д рьдә көн озынлыгы чыпчык борыны ч гыйнварда — карга адымы кадәр, февр ат башы зурлыгында. Гыйнварның ун нә көн бер ипи пешерерлек вакытка оз

Идел Болгарында күптөрле калеı лар системасы кулланылган. Аларны рысы да хуҗалык итү шартларына, гать дөньясына бәйле рәвештә конкр тәлекле һәм төзелешле булган. Хайв лендаре киң кулланылган. Анда кє

исемнәре билгеле бер тәртип белән килгән, ә еллар 12 еллык циклдан торган. Аның эчендәге еллар хайван исемнәре белән билгеләнгәннәр: тавык елы, үгез елы, арслан елы һ. б.

IX—X гасырларда Идел Болгарына Ислам дине белән бергә һиҗри календаре үтеп керә. Бу — һиҗрәттән, ягъни Мөхәммәт пәйгамбәрнең Мәккәдән Мәдинәгә күчеп киткән көненнән башлап йөртелә торган ел исәбе.

Кыр эшләренең төгәл көннәрен һәм шартларын белү ихтыяҗы ел фасылларына бәйле календарь тууына китергән, һәм айкояш календаре туган.

XVIII гасырда исә Петр I нең махсус указы белән Россиягә яңа календарь кертелә. Татарстанда ул XIX гасырның икенче яртысында гына киң кулланыла башлый.

Безнең халык тапкыр да, җор да бит ул. Һәр вакыйгага үзенең җыры, такмагы, әйтеме, әкияте яки башка бәяләмәсе бар аның. Хәзер, әйдәгез, хайван календаре кабул ителүгә кагылышлы риваятьне искә төшереп китик.

«Ел башы» киләсе булгач, кайсы хайван аны иң алдан күрсә, «Ел башы»на шул хайванның исемен бирмәкче булганнар, имеш. Дөя үзенең муены озынлыкка ышанып, иң алдан күрәм, дип торганда, бер тычкан йөгереп килеп, аның өркәченең өстенә менгән дә «Ел башы»н алдан күреп алган. Шуннан 12 еллык циклның, ягъни ел әйләнәсенең башы да тычканнан исәпләнә башлаган, имеш. Киләсе елларга башка хайваннарның исемнәре бирелгән: Тычкан, Сыер, Барс, Куян, Ләү, Елан, Елкы, Куй, Мичин, Тавык, Эт, Дуңгыз.

Әйтемнәр:

Кыш бавыры бик озын. Көз җимеше җәйдән билгеле. Җәйгә чыккан җан үлмәс. Бер елда ике яз булмый. Апрель кергәч, эт биеклеге кар ява. Февральдә сыер мөгезен сындырырлык суыклар була. Январьның көне кыска, февральнең ае кыска.

**Бишенче дәрес.** Йомгаклау. Белемнәрне ныгыту, системага салу эшләре алып барыла. Дәресне фольклор әсәрләреннән, тарихи фактлардан файдаланып, КВН яки башка төрле ярышлар формасында да үткәрергә мөмкин.

Бу мәкаләдә күп санда фольклор әсәрләре тәкъдим итү — «дәресләрдә гел халык авыз иҗаты әсәрләре генә кулланылырга тиеш икән», дигән фикер калдырмасын. Нәрсәдән ничек файдалану — укытучының үз эше. Без бары тик: астрономия фәнен укыту балаларның күңелен халкыбыз тәҗрибәсенә, акылына, зирәклегенә якынайтырга тиеш дигән фикерне әйтәбез. Шул күзлектән караганда, дәрес чикләре фольклорны гына түгел, татар халкының тарихына, мәдәниятенә, гомумән, рухи хәзинәләренә кагылышлы материалларны да бик иркен сыйдыра ала.

Халкыбызның рухи хәзинәләре белән җанландырылган дәресләр укучыларда материалга карата кызыксыну уяталар, аның аңлы үзләштерелүен тәэмин итәләр, мәктәптә укыту һәм тәрбияне халыкчан итеп оештырырга булышалар.

Күптән түгел Арчаның 10 нчы номерлы балалар бакчасы педагогик коллективының иҗат отчеты булып үтте, анда районның барлык мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләре мөдирләре һәм тәрбияче-методистлары катнашты. Кунаклар тәрбия-белем бирү эшенең куелышы, нәниләрнең тормышы белән якыннан таныштылар, дәресләрдә, төрле чараларда булдылар.

Әлеге рәсемнәрдә шушы бакчага йөрүче балаларның эшчәнлеге күрсәтелгән.

**Наил Миңлебаев** фотолары





